**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3057**
**04.05.2021**

Башкарма комитетның 2013 елның 17 июлендәге 4260 номерлы карары белән расланган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 17 июлендәге 4260 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 20 июнендәге 3598 номерлы, 2016 елның 28 июнендәге 3318 номерлы, 2018 елның 3 июлендәге 3733 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 7674 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 пунктта икенче баганаың 1 пунктчасында «яшәү урынынnan белешмә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2.6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | РФ гражданын яшәү урыны буенча теркәү турында мәгълүматлар – РФ ЭЭМ | |

3) 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтелә | 1) Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү | 210-ФЗ номерлы Федераль законның |

| | | |
|---|---|---|
| торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктalы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган | 14 статьясының 12 пункты, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов